ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«агрохимикатлар – үсемлекләрне тукландыру һәм җирнең (туфракның) уңдырышлылыгын җайга салу өчен каралган ашламалар (минераль, органик, органик-минераль, микробиологик), химик мелиорантлар. Органик һәм органик-минераль ашламалар җитештерү өчен кулланыла торган торф, терлекчелек һәм үсемлекчелек калдыклары, терлекчелекнең эшкәртелмәгән һәм яңадан эшкәртү узмаган икенчел продуктлары, ләм, агым сулар утырмасы, катнаш минераль ашламалар агрохимикатлар булып саналмый;»;

в) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«пестицидлар – үсемлекләрнең үсешен көйләү, феромоннар, дефолиантлар, десикантлар һәм фумигантлар буларак та кулланыла торган матдәләр яисә матдәләр катнашмасы һәм корткыч организмнарга каршы көрәшү өчен каралган химик һәм биологик препаратлар;»;

г) унөченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4 статьяның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үз милкендә яисә файдалануында булган җир кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгы җирләренең деградацияләнү, туфрак пычрану фактлары турында башкарма хакимиятнең тиешле органнарына хәбәр итәргә;»;

3) 7 статьяның бишенче абзацында «эрозиягә каршы чаралар комплексын керткән,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 61-ТРЗ